Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге Советы өченче чакырылыш карары.

№ 125

Олы Әтнә авылы 09.10.2019 ел.

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Олы Әтнә авыл җирлеге биләмәсендә үзара салым җыю һәм куллану буенча җирле референдум үткәрү көнен билгеләү турында.

2002 елның 12 июнендә кабул ителгән «Россия Федерациясе гражданнарының референдумда катнашу һәм сайлау хокукларының төп гарантияләре »турындагы 67 номерлы Федераль законның 15 статьясы, 2003 елның 6 октябрендә кабул ителгән «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның уртак принциплары» турындагы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, 2004 елның 23 мартында кабул ителгән «Җирле референдум үткәрү» турындагы 23 номерлы Татарстан Республикасы законының 12 статьясы, Олы Әтнә авыл җирлеге Уставынын 11 статьясы, Олы Әтнә авыл җирлеге башкарма комитеты 2019 елның 01 октябрендә кабул ителгән 31 номерлы карары, Олы Әтнә авыл җирлеге Советының 2019 елнын 01 октябрендә кабул ителгән 121 номерлы карары нигезендә Олы Әтнә авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге биләмәсендә үзара салым җыю һәм куллану буенча 2019 елның 01 декабрендә референдум үткәрергә .

2. Җирле референдумда караласы мәсьәләне расларга:

«Сез, «Олы Әтнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге биләмәсендә даими теркәлгән , 18 яше тулган һәр кешедән 2019 елда 500 ( биш йөз ) сум күләмендә гражданнарга үзара салым кертү һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне кушымта итеп бирелгән чаралар исемлеге белән килешәсезме.

Үзара салым акчасы тотыла торган төзекләндерү буенча чаралар исемлеге:

1.Олы Әтнә, Яңа Әтнә, Яңа Җөлби, Кече Әтнә, Шәкәнәч авылларындагы урам юлларын ремонтлау һәм төзекләндерү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;

2. Олы Әтнә, Яңа Әтнә, Яңа Җөлби, Кече Әтнә, Шәкәнәч авыллары территорияләрен төзекләндерү (яшелләндерү, агачлар, куаклар кисү , кисү материаллары һәм чүп-чардан чистарту) ;

3.Олы Әтнә, Кече Әтнә, Яңа Әтнә авылларында урамнарны яктырту һәм яктырткычлар, материаллар сатып алу (яктырткычларны, чыбыкларны ремонтлау, лампаларны алыштыру) буенча хезмәт күрсәтү;

4. Олы Әтнә авылыда «Атниннка» елгасынын яр буен төзекләндерүне проектлаштыру;

5.Олы Әтнә, Кече Әтнә, Шәкәнәч авылларында җирләнгән урыннарны (зиратлар) төзекләндерү (коймаларны ремонтлау, агачлар, куаклар кисү, кисү материалларыннан һәм чүп-чардан чистарту) һәм аларны карап тоту.;

6.Олы Әтнә авылында базар территориясен коймалар белән каплау, юлын түшәү

ӘЙЕ ЮК»

3. Олы Әтнә авыл җирлеге сайлау комиссияләренә «Олы Әтнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге биләмәсендә гамәлдәге законнар нигезендә референдум үткәрүне оештырырга.

4. Аерым юнәлешләр буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаны экономияләгән очракта, әлеге акчалар планлаштырылган эшләрне башкару өчен җитәрлек булмаган юнәлешләрне финанслауга җибәрелә.

5. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында урнаштыру, «Әтнә таңы» район газетасында бастырып чыгару һәм рәсми сайтта http://atnya.tatarstan.ru. урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә .

Татарстан Республикасы
Әтнә муниципаль районы
Олы Әтнә авыл җирлеге башлыгы Г.Г.Хакимов